Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXII-3**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 23 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләрен түләүсез бирүне (тапшыруны) җайга сала торган аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

“Дәүләт социаль ярдәме турында” 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы, 2015 елның 29 декабрендәге 388-ФЗ номерлы “Россия Федерациясенең аерым закон актларына адреслылык һәм мохтаҗлык критерийларын куллану принцибын үтәү бурычыннан чыгып социаль ярдәм чараларын күрсәтүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында” 2015 елның 29 декабрендәге 388-ФЗ номерлы Федераль законнар, “Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 14 февралендәге 181 номерлы карары нормаларын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Уставы нигезендә, Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 маддәсе нигезендә “Җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукы булган гражданнарга милек итеп бирү (тапшыру) тәртибе турында” 2012 елның 27 гыйнварындагы XIV-3 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2012 елның 12 июлендәге XVIII-13 номерлы, 2017 елның 15 февралендәге XVI-4 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлектәге 1.1, 1.2 пунктларны өстәргә:

“1.1. Гарантияләр, хокуклар һәм ташламалар бирүче органнар әлеге гарантияләр, хокуклар һәм ташламалар бирү турында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә файдалану юлы белән һәм ЕГИССО (Бердәм дәүләт социаль тәэминат мәгълүмат системасы) операторы билгеләгән форматларга туры китереп мәгълүмат бирүне тәэмин итәләр.

1.2. Әлеге карарда күрсәтелгән (бирелә торган) категорияләрдәге гражданнарга бирелгән гарантияләр, хокуклар һәм ташламалар турында мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә ЕГИССОдан файдалану һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматларга туры китереп алынырга мөмкин.”.

2. “Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 маддәсе нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукына ия гражданнарга милеккә бирү турында” 2012 елның 5 сентябрендәге XIX-7 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 2.1, 2.2 пунктлар өстәргә:

“2.1. Әлеге карар нигезендә гарантияләр, хокуклар һәм ташламалар бирүче органнар күрсәтелгән гарантияләрне, хокукларны һәм ташламаларны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә, һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - ЕГИССО) куллану юлы белән бирү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәләр.

2.2. Әлеге карарда күрсәтелгән гражданнар категорияләренә бирелгән (бирелә торган) гарантияләр, хокуклар һәм ташламалар турында мәгълүмат ЕГИССО Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә, һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә ЕГИССО куллану юлы белән алынырга мөмкин.”.

3. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының оештыру бүлегенә әлеге карарның күчермәсен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Россия Пенсия фонды идарәсенә җибәрергә.

6. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г. Вәлиев